КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 сентябрь г.Казань № 921

Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче карары белән расланган Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 31 октябрь, 970 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 5 август, 555 нче карары белән расланган Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 31 октябрь, 992 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 586 нчы карарындагы 3 пункты.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин